СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.12.2021 Баулы шәһәре № 90

Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 20 апрелендәге «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»гы 149 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 17 декабрендәге 1087 номерлы карары нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 20 апрелендәге «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»гы 149 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 28 сентябрендәге 176 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 274 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемдә «даими нигездә» сүзеннән соң «контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторлары,» сүзләрен өстәргә;

1 абзацның 1 пунктында өч «11 163,0» санын «11 498,0» санына алмаштырырга;

2 пунктта:

өченче абзацта «рәисе» сүзеннән соң «, рәис урынбасары, аудиторлар» сүзләрен өстәргә;

3.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Баулы муниципаль районының контроль-хисап палатасы рәисе урынбасарына, айлык акчалата түләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләүдән тыш, ай саен акчалата премияләр, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнергә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта аларның акчалата түләүләренең айлык җыелма күләме Баулы муниципаль районының контроль-хисап палатасы рәисенә айлык акчалата түләүләрнең 0,8 күләменнән арта алмый.

Баулы муниципаль районының контроль-хисап палатасы аудиторларына, айлык акчалата түләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләүдән тыш, айлык акчалата бүләкләүләр, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнергә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Бу чакта аларның акчалата түләүләренең айлык җыелма күләме Баулы муниципаль районының контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата түләүләрнең 0,6 айлык җыелма күләменнән арта алмый.»;

күрсәтелгән карарга 1 нче кушымтада:

«Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе, контроль орган аудиторы» юлының 1нче графасында “контроль орган аудиторы” сүзләрен төшереп калдырырга;

күрсәтелгән карарга 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

7 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәргә:

«* Муниципаль хезмәткәр ул элек биләгән вазыйфалар төркеменә караганда югарырак төркемгә керә торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән очракта, ул биләгән вазыйфа керә торган вазыйфалар төркеме өчен беренче классклы чин бирелгәнче оклады күләмен вазыйфаи окладка 3 процентка тигез булган процентлы ставкадан исәпләнә.

Муниципаль хезмәткәр элек биләгән вазыйфаларның түбәнрәк төркеменә караган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнсә һәм элек биләгән вазыйфасы буенча аңа класс чины бирелгән очракта, класс чины өчен оклад күләме вазыйфаи окладка 7 процентка тигез процентлы ставкадан чыгып исәпләнә;».

Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт Вазыйфаларының элек биләгән төркеменә караган муниципаль хезмәткәр вазыйфасына билгеләнсә һәм элек биләгән

вазыйфасы буенча аңа класс чины бирелгән булса, класс чины өчен оклад күләмен исәпләү вазыйфаи окладка процентлы ставкадан чыгып, 7 процентка тигез итеп башкарыла.».

2. Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә тормышка ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 149 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 28 августындагы 274 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

әлеге карарның гамәлдә булу вакыты 2021 елның 4 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла (әлеге карарның 1 пунктының өченче - бишенче абзацларыннан тыш, алар 2018 елның 1 апреленнән гамәлдә булган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла).

Баулы муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы, район Советы
Рәисе вазыйфаларын башкаручы –
район башлыгы урынбасары, Советы
Рәисе урынбасары — Р.Г. Хәмидуллин

Баулы муниципаль районы
Советының 2021 елның 14 декабрендәге
90 номерлы карарына
1 нче кушымта

“Баулы муниципаль районы
Советының 2018 елның 20 апрелендәге
149 номерлы карарына
2 нче кушымта

Муниципаль район башлыгының, муниципаль район башлыгы урынбасарының, муниципаль район контроль-хисап палатасы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторларының акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 4 төркем |
| Муниципаль район башлыгы | 31 966 |
| Муниципаль район башлыгы урынбасары | 28 767 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 28 767 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары | 25 871 |
| Контроль-хисап палатасы аудиторы | 20 927 |